| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРЖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2022 г. Агрыз № 21-1

"Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2021 елның 1 июлендәге 289-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2021 елның 19 ноябрендәге 376-ФЗ номерлы, "Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законга таянып һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 30 декабрендәге 492-ФЗ номерлы, "Муниципаль норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү кирәклеге турында" 29.04.2022 елның 02-01-18-2022 номерлы Федераль законнарын, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасы һәм "Россия Федерациясе прокуратурасы турында" 17.01.1992 елның 2202-I номерлы Федераль законның 9 статьясы тәртибендәге мәгълүматны исәпкә алып, Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләрне икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге карарны дәүләт теркәве өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») район газетасында дәүләт теркәвеннән соң бастырып чыгарырга, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталында «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар», (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башлыгы урынбасары И.И. Ямалиевка йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022 елның 16 ноябрендәге 21-1 номерлы карарына кушымта

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр**

1. 6 статьяның 1 өлешендәге 35 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«35) "Федераль милектә булган су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне үтәүне тәэмин итү;».

2. 8 статьяның 23 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«23) «Федераль милектә булган су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне үтәүне тәэмин итү;»;».

3. 19 нчы статьяда:

3.1. 5 нче өлешне киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5. Ачык тыңлауларны үткәрү турында карар, шулай ук халык алдында тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, халык алдында тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 календарьдан да соңга калмыйча «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында, шул исәптән Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталы составында (http://agryz.tatarstan.ru), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.»;

3.2. 6 нче өлешне киләсе редакциядә бәян итәргә:

«6. Халык алдында тыңлаулар үткәрү һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты турында мәгълүмат бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көннән башлап, районда яшәүчеләр халык алдында тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә яки муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша район башлыгына җибәрергә хокуклы.».

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр юнәлеше ачык тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Район башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне гомумиләштерүне оештыра һәм аларны ачык тынлауларда катнашучыларга җиткерә.»;

3.3. 9 нче өлешне киләсе редакциядә бәян итәргә:

«9. Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, шул исәптән Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында

(http://agryz.tatarstan.ru) һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында ачык тыңлаулар уздырылган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.»;

3.4. 19 статьяның 10 өлешен киләсе редакциядә бәян итәргә:

«10. Ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе әлеге Устав һәм район Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә, алар муниципаль берәмлек халкына ачык тыңлаулар уздыру вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан ук таныштыруны, шул исәптән аны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында (алга таба әлеге статьяда - рәсми сайт), "Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба әлеге статьяда - Бердәм портал) алдан танышуны, муниципаль берәмлек кешеләренең муниципаль хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен, шул исәптән рәсми сайт, бердәм портал ярдәмендә, муниципаль берәмлек халкының ачык тыңлауларында катнашуын тәэмин итә торган башка чаралар, кабул ителгән карарларны дәлилләнгән нигезләүне дә кертеп, ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгару (халыкка җиткерү), шул исәптән аларны рәсми сайтта, Бердәм порталда Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә урнаштыру юлы белән, бастырып чыгару (халыкка җиткерү) мөмкинлеген күздә тота.».

4. 45 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктның ун һәм унбер абзацларын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«-«Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре төзү өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү;

- «Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү;».

5. 54 статьяның 3 өлеше киләсе редакциядә бәян ителергә:

«3. Районның финанс-бюджет палатасы рәисе үз вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан билгеләнеп куела.

Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында башкарыла. Күрсәтелгән тикшерүне уздыруда Татарстан Республикасы финанс органының катнашу тәртибе «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта белән билгеләнә.».